**Казан шәһәре Думасының**
**2024 елның 18 декабрендәге 7-35 номерлы карары**

**Казан шәһәре Думасының 2008 елның 18 февралендәге 13-28 номерлы «Казан шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен һәм аларны башкару тәртибен билгеләү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Казан шәһәренең муниципаль хезмәткәрләрен социаль гарантияләр белән тәэмин итү максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы “Татарстан Республикасындагы җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазифаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карарына таянып, Казан шәһәре Думасы карар бирде:

1. Казан шәһәре Думасының 2008 елның 18 февралендәге 13-28 номерлы «Казан шәһәре муниципаль хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмен билгеләү һәм аларны түләү тәртибен билгеләү турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Думасының 2008 елның 14 августындагы 17-32 номерлы, 2009 елның 12 мартындагы 10-39 номерлы, 2009 елның 11 июнендәге 15-41 номерлы, от 2010 елның 8 октябрендәге 4-54 номерлы, 2011 елның 14 сентябрендәге 16-7 номерлы, 2011 елның 22 сентябрендәге 20-7 номерлы, 2012 елның 7 июнендәге 21-14 номерлы, 2012 елның 24 октябрендәге 9-17 номерлы, от 2013 елның 29 маендагы 8-23 номерлы, 2013 елның 16 октябрендәге 17-25 номерлы, 2014 елның 16 апрелендәге 14-32 номерлы, 2014 елның 25 декабрендәге 10-40 номерлы, 2016 елның 21 гыйнварындагы 16-4 номерлы, 2016 елның 14 декабрендәге 26-12 номерлы, 2017 елның 25 февралендәге 10-13 номерлы, 2017 елның 17 августындагы 12-19 номерлы (2017 елның 27 сентябрендәге редакциядә), 2017 елның 15 ноябрендәге 12-21 номерлы, 2017 елның 13 декабрендәге 10-22 номерлы, 2018 елның 17 апрелендәге 14-25 номерлы, 2019 елның 20 июнендәге 15-34 номерлы, 2020 елның 12 августындагы 5-41 номерлы, 2020 елның 21

сентябрендәге 19-1 номерлы, 2022 елның 13 октябрендәге 4-17 номерлы, 2022 елның 19 декабрендәге 23-19 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 6-30 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), аның 1 номерлы кушымтасын әлеге карар кушымтасы нигезендә редакцияләп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2024 елның 18 декабрендәге
7-35 номерлы карарына
кушымта

**Муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи окладлары күләмнәре**

| № т/б | Вазифа атамасы | Вазифаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе | 50225 |
| 2 | Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары | 49104 |
| 3 | Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары | 49104 |
| 4 | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе | 47845 |
| 5 | Казан шәһәре Башкарма комитетының район(-нар) администрациясе башлыгы | 49104 |
| 6 | Казан шәһәре Башкарма комитетының территория префекты | 49104 |
| 7 | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының эшләр белән идарә итүчесе | 41168 |
| 8 | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе урынбасары | 41168 |
| 9 | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының эшләр белән идарә итүчесе урынбасары | 32876 |
| 10 | Казан шәһәре Думасы аппаратының идарә башлыгы, Казан шәһәре Башкарма комитетының идарә җитәкчесе, комитет рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының идарә җитәкчесе, комитет рәисе | 36654 |
| 11 | Казан шәһәре Башкарма комитетының идарә җитәкчесенең беренче урынбасары, комитет рәисенең беренче урынбасары | 32876 |

| № т/б | Вазифа атамасы | Вазифаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 12 | Казан шәһәре Башкарма комитетының идарә җитәкчесе урынбасары, комитет рәисе урынбасары | 32876 |
| 13 | Казан шәһәре Думасы аппаратындагы идарә башлыгының беренче урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратындагы идарә башлыгының беренче урынбасары, комитет рәисенең беренче урынбасары | 32876 |
| 14 | Казан шәһәре Думасы аппаратының идарә башлыгы урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының идарә башлыгы урынбасары, комитет рәисе урынбасары | 32876 |
| 15 | Казан шәһәре Башкарма комитетының район (-нар) администрациясе башлыгының беренче урынбасары | 36654 |
| 16 | Казан шәһәре Башкарма комитетының район (-нар) администрациясе башлыгы урынбасары | 36155 |
| 17 | Казан шәһәре Башкарма комитетының территория префектының беренче урынбасары | 36654 |
| 18 | Казан шәһәре Башкарма комитетының территория префекты урынбасары | 36155 |
| 19 | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының мөстәкыйль бүлек башлыгы | 34696 |
| 20 | Казан шәһәре Думасы аппаратының, Казан шәһәре Контроль-хисап палатасы аппаратының мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) | 34696 |
| 21 | Казан шәһәре Башкарма комитетының район (-нар) администрациясе аппараты җитәкчесе | 36513 |
| 22 | Казан шәһәре Думасы аппаратының, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының, Казан шәһәре контроль-хисап палатасы аппаратының мөстәкыйль бүлеге башлыгы урынбасары | 29379 |
| 23 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы киңәшчесе | 25742 |

| №<br>т/б | Вазифа атамасы | Вазифаи оклад күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| 24 | Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе киңәшчесе | 25742 |
| 25 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы ярдәмчесе | 25742 |
| 26 | Казан шәһәре Думасы аппаратының идарәсе составындагы бүлек башлыгы, Казан шәһәре Башкарма комитеты идарәсе, комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты составындагы бүлек башлыгы | 25742 |
| 27 | Казан шәһәре Башкарма комитетының район (-нар) администрациясендәге, Казан шәһәре Башкарма комитетының территория префектурасындагы бүлек башлыгы | 25742 |
| 28 | Казан шәһәре Башкарма комитеты идарәсе, комитеты, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты составындагы сектор мөдире | 25323 |
| 29 | Казан шәһәре Контроль-хисап палатасы аппаратының баш инспекторы | 25323 |
| 30 | Казан шәһәре Башкарма комитетындагы, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратындагы идарә, комитет составындагы бүлек башлыгы урынбасары | 25323 |
| 31 | Казан шәһәре Башкарма комитетының район (-нар) администрациясе бүлеге башлыгы урынбасары | 25323 |
| 32 | Баш белгеч | 24622 |
| 33 | Казан шәһәре Контроль-хисап палатасы аппаратының әйдәүче инспекторы | 24622 |
| 34 | Әйдәүче белгеч | 22524 |
| 35 | 1 категорияле белгеч | 20006 |

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**